**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«25»10 2021 ел Яр Чаллы № 3770

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә урнашкан «Алабуганефть» акционерлык җәмгыятенең кабул итү һәм салу пункты төзелеше» объекты буенча территорияне планлаштыру проектын һәм межалау проектын эшли башлау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 бүлеге нигезендә, Мәләкәс авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, район Уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә урнашкан «Алабуганефть» акционерлык җәмгыятенең кабул итү һәм салу пункты төзелеше» объекты буенча территорияне планлаштыру проектын һәм межалау проектын эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре нигезендә техник регламентлар таләпләренә таянып алып барырга.
3. Әлеге карарны районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин